ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО
ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАЛТАЧ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 22» июля 2019 г. № 11

Басма сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен
махсус урыннар (махсус урын) бирү һәм җиһазлау турында

Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен, һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү һәм урнаштыру турында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү турында» гы 10 июль 2019 ел 67/516 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге башлыгы карар бирә:

1. Һәрбер сайлау участогы территориясендә басма сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар (махсус урын) бирергә һәм җиһазларга 1 кушымта нигезендә.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитетына кушымта нигезендә басма сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар (махсус урын) булдырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында baltasi.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем өстемә алам.

Балтач шәһәр җирлеге башлыгы Р.Р.Нотфуллин

Норма авыл җирлеге башлыгы
карарына кушымта
“2019 елның 22 июле” № 11

Басма сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен
махсус урыннар исемлеге

| Сайлау участогы номеры | Басма сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар алресы | Элү урыны исеме (махсус җиһазландырылган конструкция, мәгълүмат стенды (реклама щиты, тумба), бина диварында, фойеда һәм тд.) |
|---|---|---|
| 1088 | Балтач шәһәр тибындагы поселок, В.Булатова урамы 22 нче йорт | мәгълүмат стенды |
| 1089 | Балтач шәһәр тибындагы поселок, Ленин урамы 4/1 нче йорт | мәгълүмат стенды |
| 1090 | Балтач шәһәр тибындагы поселок, Ленин урамы 49 нчы йорт | мәгълүмат стенды |
| 1092 | Балтач шәһәр тибындагы поселок, Ленин урамы 126 нчы йорт | мәгълүмат стенды |
| 1284 | Балтач шәһәр тибындагы поселок, Ленин урамы 63 нчы йорт | мәгълүмат стенды |